Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАРЫ

20 октябрь 2022 ел №15

Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 12 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгын куркынычсызлыгы турында»1994 елның 18 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә

Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 29 декабендәге 12 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

I бүлекнең 3 пункты тугызынчы абзацында «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү,» сүзләрен «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү юллары турында хәбәр итү,» сүзләренә, «җайланма» сүзен «уздыру» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Бишмунча авылы, Совет урамы, 57 нче а йорт, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26 а йорт, Бакчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1 йорт, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Бишмунча авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г.Фазлыев